КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 октябрь г.Казань № 897

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһаз-ландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 май, 335 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһаз-ландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 май, 335 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү»

Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1710 нчы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына караган дәүләт милкенең (муниципаль милекнең) коммуналь һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә булышлык күрсәтү»нең төп чаралары кысаларында Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендә булган һәм федераль максатчан программаларга кертелмә гән капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен җирле бюджетларга аларга карата Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы баш эш итүче итеп билгеләнгән федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү тәртибенең 4 пунктындагы «а» пунктчасында «Россия Федерациясе субъектларына караган дәүләт милкенең (муниципаль милекнең) коммуналь һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә булышлык күрсәтү» чарасына» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) коммуналь һәм инженерлык инфраструктурасын модернизацияләүгә ярдәм итү» ведомство максатчан программасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин